# Әтнә районы Түбән Көек төп белем мәктәбе
# Башлангыч профсоюз оешмасының
# 2019-2024 нче еллардагы эшчәнлеге буенча
# Хисап комиссиясе отчёты.

Әтнә районы **Түбән Көек төп белем** мәктәбе башлангыч профсоюз оешмасының Хисап комиссиясе 2019 нчы елда узган отчет-сайлау җыелышында 3 кеше составында сайланып куелган. Комиссия рәисе: Хисматуллин И.Р., членнары Галиәхмәтова Г.Н., Шакирова Ф.Ф.

Хисап комиссиясе эшчәнлеге Россия Федерациясенең халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре профсоюзы Уставына, Россия Федерациясенең «Профессиональ союзлар, аларның хокуклары һәм эшчәнлек гарантияләре турында» гы законына, гамәлдәге законнарга нигезләнеп оештыра.

Хисап комиссиясенең төп вәкаләте башлангыч профсоюз оешмасының финанс-оештыру эшчәнлеген контрольләүне тәэмин итү:

-оешмадагы профсоюз членлыгын контрольдә тоту;

-башлангыч профсоюз оешмасы счетына 1% профсоюз взносларының даими күчерелүен белешеп тору;

-һәр профсоюз члены АИС автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлгән булуын тәэмин итү;

- яңа эшкә кабул ителгән хезмәткәрләрнең вакытында учетка теркәлүен барлау;

-профсоюзга керү турында гаризаларның дөрес тутырылуын күзәтеп бару;

- профсоюз членнарына электрон профсоюз билетлары тапшыру учетын барлап бару;

-профсоюз счетындагы акчаларның дөрес һәм максатчан файдалануын булдыру;

-профсоюз комитеты документларын даими рәсмиләштереп баруны контрольләү;

-профсоюз членнарыннан кергән мөрәҗәгатьләрне һәм тәгъдимнәрне вакытында карап чара күрүне тәэмин итү.

Коллективта эшләүче хезмәткәрләрнең барысы да башлангыч профсоюз оешмасында профсоюз члены булып теркәлгән. Бу сан коллективта 100% профсоюз членлыгын күрсәтә.

Мәгариф бүлегенең мәгариф оешмаларының үзәкләштерелгән бухгалтериясе тарафыннан ай саен членлык взнослары Әтнә территориаль профсоюз оешмасы счетына күчерелеп бара.Ул акчалар башлангыч профсоюз оешмасы счетына утыртыла. Район семинарлары вакытында территориаль профсоюз оешмасы бухгалтеры профком рәисләре алдында отчет тота.Һәр башлангыч профсоюз оешмасы рәисенә счеттагы суммалар (керемнәр һәм чыгымнар) буенча Исәп-хисап кәгазьләре тапшырыла.

Ел саен профком утырышында профсоюз оешмасының яңа календар елга Керемнәр һәм чыгымнар сметасы төзелеп, раслана. Сметада мәдәни-массакүләм, спорт-сәламәтләндерү чараларын үткәрү, хезмәтне саклауга, информацион

эшчәнлекне оештыруга юнәлдерелгән чыгымнарга, профсоюз членнарының юбилейларын билгеләп үтү, аларның шәхси гаризалары буенча матди ярдәм күрсәтү өчен акчалар каралган.

Ел дәвамында Хисап комиссиясе катнашында профком утырышларында профком рәисе тотылган акчалар буенча исәп-хисап ясый. Аерым чарага акча тоту мәсьәләсе профком утырышында каралып үтә, утырыш карары чыгарыла. Карарга нигезләнеп, территориаль профсоюз оешмасына акчаның тотылу максаты,суммасы күрсәтелгән заявка бирелә. Әтнә территориаль профсоюз оешмасы бухгалтеры акчаны аванс документы белән рәсмиләштереп өләшә. Утырыш карарына өстәп тотылган акчаларның чыгымнарын дәлилләүче финанс документлар теркәлә.

Профсоюз членнарына аларның шәхси гаризалары нигезендә матди ярдәм күрсәтү каралган. Матди ярдәм профсоюз членнарының сәламәтлекләрен ныгыту максатыннан , озак вакыт эшкә сәләтсезлек , инвалидлык , бәла-казаларга юлыгу очракларында бирелә. Соңгы елларда бу максатка:

-2020 нче елда 1 профсоюз членына 1000 сум, (Шәмсиева Рәмилә)

-2021 нче елда 1 профсоюз членына 1000 сум, (Загидуллина Рузалия)

-2022 нче елда 1 профсоюз членына 1000 сум, (Сәйфетдинова Рауза)

СВО да катнашкан балалары һәм гаилә членнары булган хезмәткәрләргә 2022 нче елда 1000 сумлык матди ярдәм бирелде.

Сметада каралган мәдәни-массакүләм, спорт-сәламәтләндерү чараларын үткәрүгә төп суммалар расходлана.

Мәсәлән, 2023 нче елда :

-мәдәни-массакүләм чараларга – 20300 сум акча тотылган. Профсоюз счетыннан профсоюз членнарына Укытучылар көне, (*Мәктәпкәчә белем бирү хезмәткәре көне, Поварлар коне,)*профсоюз членнарына Яңа ел бүләкләре, Ватанны саклаучылар көне, 8 Март бәйрәме уңаеннан бүләкләр әзерләнгән. Юбилей даталарына атап хезмәткәрләргә тантаналы төстә коллектив исеменнән бүләкләр тапшырылган. Бу уңайдан ветеран – укытучылар, хезмәткәрләр дә игътибарсыз калмаган.

Шул ук вакытта, хезмәтне саклауга юнәлдерелгән чыгымнар булмаган.

Ел да башлангыч профсоюз оешмасы исеменә “Учительская газета”сының кушымтасы “Мой профсоюз” газетасы яздырыла.

Профсоюз комитетының төп документлары даими дөрес итеп тутырылып рәсмиләштерелеп барыла. Профком утырышы карарларының үткәрү датасы,номеры күрсәтелгән,куллар һәм оешма печате куелган. Профком утырышы карарлары аерым папкага теркәлгән, папканың башлану срогы күрсәтелгән. Профсоюз җыелышлары утырышлары рәсмиләштерелеп бара.

Профсоюз комитетында Профсоюз членнарыннан кергән мөрәҗәгатьләрне һәм тәгъдимнәрне теркәү журналы булдырылган. Язма һәм телдән кергән мөрәҗәгатьләргә вакытында карап чара күрелеп барыла.